**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге вазгыятьне контрольдә тоту советы составына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге вазгыятьне контрольдә тоту советын төзү турында» 2010 елның 3 февралендәге ПУ-41 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 3 июнендәге ПУ-363 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге ПУ-889 номерлы, 2011 елның 23 мартындагы ПУ-144 номерлы, 2011 елның 3 ноябрендәге ПУ-699 номерлы, 2012 елның 5 июлендәге ПУ-539 номерлы, 2012 елның 13 октябрендәге ПУ-874 номерлы, 2012 елның 5 декабрендәге ПУ-1020 номерлы, 2013 елның 4 ноябрендәге ПУ-1073 номерлы, 2014 елның 6 сентябрендәге ПУ-840 номерлы, 2014 елның 15 октябрендәге ПУ-986 номерлы, 2014 елның 24 октябрендәге ПУ-1004 номерлы, 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 28 гыйнварындагы ПУ-54 номерлы, 2015 елның 25 июлендәге ПУ-679 номерлы, 2016 елның 12 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы, 2016 елның 3 февралендәге ПУ-100 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-461 номерлы, 2018 елның 25 гыйнварындагы ПУ-90 номерлы, 2018 елның 2 мартындагы ПУ-201 номерлы һәм 2018 елның 21 апрелендәге ПУ-327 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында алкогольле һәм спиртлы продукция әйләнеше өлкәсендәге вазгыятьне контрольдә тоту советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан В.Е. Махеевны чыгарырга;

б) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

В.А. Леоновның – «Татарстан Республикасы спорт министры»;

А.Р. Мостафинның – «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм кулланучылар базары идарәсе башлыгы урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 13 октябрь
№ ПУ-730